РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

*Постановление* *Карар*

**29.09.2021** **г.Чистополь** **188**

Чистай шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 29 июлендәге 112 номерлы
«Агачларны һәм куакларны кисүгә, утыртуга,
күчереп утыртуга, аларның ябалдашларын
формалаштырып кисүгә, газонны бетерүгә
рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында» карары
белән расланган агачларны һәм куакларны кисүгә,
утыртуга, күчереп утыртуга, аларның ябалдашларын
формалаштырып кисүгә, газонны бетерүгә
рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 112 номерлы турында «Агачларны һәм куакларны кисүгә, утыртуга, күчереп утыртуга, аларның ябалдашларын формалаштырып кисүгә, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган агачларны һәм куакларны кисүгә, утыртуга, күчереп утыртуга, аларның ябалдашларын формалаштырып кисүгә, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «агачларның, куакларның авариясе турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «яисә гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне (авария хәлендәге агачларны) бетерү кирәклеге турында яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә расланмау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында «(авария-торгызу эшләрен башкару яисә яшел үсентеләрне бетерү очракларыннан тыш (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) сүзләрен төшереп калдырырга;
1.6. 2.8.4 пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;
1.7. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «, шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру яисә яшел үсентеләрне бетерү өчен (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт алган очракта)» сүзләрен төшереп калдырырга;
1.8. 3.5.2.3 пунктын төшереп калдырырга;
1.9. 3.5.5 пунктта «; авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә яшел үсентеләрне бетергәндә муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) - ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;
1.10. Регламентның 2 нче кушымтасында «Авария агачлары кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садыйковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов